**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Олыяз авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2024 елның 7 ноябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Югары Казаклар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2024 елның 29 ноябренә 11 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Югары Казаклар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Югары Казаклар авылы, 1 Май урамы, 23 адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2025 елда Кукмара муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге Югары Казаклар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (яктырткычлар сатып алу);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( юлларны кышкы карап тоту, смета документациясен төзү);
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү ( янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру, смета документациясен төзү);
- халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерү һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (территорияне планлаштыру , балалар өчен уен җиһазлары сатып алу һәм урнаштыру, смета документлары төзү)?

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Олыяз авыл җирлеге башкарма комитететын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Маликов